МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 183/о

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

«11» 11 2020

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Юридик бүлеккә, дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан ун эш көне эчендә аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының:

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 14 декабрендәге 222/о-1 номерлы боерыгын;

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 29 июнендәге 114/о номерлы боерыгын;

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 14 декабрендәге 222/о-1 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 6 апрелендәге 71/о номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 14 декабрендәге 222/о-1 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 4 апрелендәге 59/о номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 14 декабрендәге 222/о-1 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 17 октябрендәге 181/о номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның «11» 11 №183/о номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Административ регламент) капиталь төзелеш объектын төзү Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районы, шәһәр округы) территориясендә гамәлгә ашырылган булса һәм ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектын үзгәртеп корган очракта, төбәк яки муниципальара билгеләнештәге автомобиль юлларын, шулай ук хосусый автомобиль юлларын төзүдән, үзгәртеп корудан тыш, әгәр төзү, үзгәртеп кору ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә гамәлгә ашырылган булса, һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) 51 статьясының 5 өлешендә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче булып төзүче оешма яки техник заказчы функцияләрен башкаручы физик яки юридик затлар катнаша ала.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Министрлыкның социаль-мәдәни объектлар төзү бүлеге (алга таба – вәкаләтле бүлекчә).

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 10.

Вәкаләтле бүлекчә урнашкан урын: Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 10, 4 нче кат, 411 нче каб.

Министрлыкның эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

«Кремль» тукталышына кадәр җәмәгать транспортында 98 номерлы автобус белән килергә; «Университет» туктатылышына кадәр:

- 8, 10, 10а, 30, 35, 54, 63, 91, 99а номерлы автобуслар;

- 7, 17, 20, 21 номерлы троллейбуслар.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Вәкаләтле бүлекчәнең белешмә телефоннары: 231-14-57, 231-15-02.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба - «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы:

http://www.minstroy.tatarstan.ru, электрон почта адресы: msagkh@tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шулай ук вәкаләтле бүлекчә урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алучы, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша;

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.minstroy.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә);

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Министрлык урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы турында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк урнашкан урын һәм аның эш графигы турындагы мәгълүмат вәкаләтле бүлекчә белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Административ регламент (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.

Мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Административ регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3-2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчасында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып тора торган), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турында килешүгә туры китереп күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба - гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертү өчен рөхсәтләр бирү, әгәр капиталь төзелеш объектын төзү ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә гамәлгә ашырылган булса, һәм ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объекты үзгәртеп корылган очракта, төбәк яки муниципальара билгеләнештәге автомобиль юлларын, шулай ук хосусый автомобиль юлларын төзү, үзгәртеп корудан тыш, әгәр төзүне, үзгәртеп кору ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль район, шәһәр округы) территориясендә гамәлгә ашырылган булса, һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 5 өлешендә һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш (алга таба – объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт, рөхсәт) | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәнең (алга таба – Министрлык турында нигезләмә) 3 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы | Министрлык турында нигезләмәнең 3 бүлеге |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт.<br>Норматив хокукый актларның конкрет нигезләмәләренә сылтама ясап, баш тарту сәбәпләрен дәлилләнгән нигезләп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша, электрон адреска, факс буенча) җибәрү рөхсәт имзалаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны һәм теркәлә торган документларны Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Министрлыкка тапшыру тәэмин ителә. Рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү процедурасын гамәлгә ашыру вакытына күпфункцияле үзәктә гариза булган вакыт һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктән Министрлыкка тапшыру вакыты кертелми | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясының 5 өлеше |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән | Рөхсәт бирү турында гариза.<br>Гариза мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән яки Министрлык адресына почта юлламасы белән тапшырыла. Гариза кулдан, машинада җыю ысулы белән яки компьютер ярдәмендә тутырыла һәм, мөһер булганда, мөрәҗәгать итүченең мөһере белән таныклана. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.<br>Гаризага түбәндәгеләр теркәлә: | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясының 3 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләнүе турында килешү, гавами сервитут билгеләнүе турында карар;<br>2) төзелешкә рөхсәт алу өчен бирелгән җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы яки, линияле объектны төзегән, үзгәртеп корган очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру буенча документация таләп ителми торган очраклардан тыш), урнаштырылуы өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителми торган линияле объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты;<br>3) төзелешкә рөхсәт;<br>4) капиталь төзелеш объектын кабул итү акты (төзелешне, үзгәртеп коруны төзелеш подряды килешүе нигезендә гамәлгә ашырган очракта);<br>5) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объекты параметрларының проект документациясенә (проект документларының РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе өлешендә), шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җиһазлары белән тәэмин ителү таләпләренә җавап бирүен раслаучы һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан (төзелешне гамәлгә ашыручы зат һәм төзүче оешма тарафыннан яки, төзелешне, үзгәртеп коруны килешү нигезендә гамәлгә ашырган очракта, техник заказчы тарафыннан, шулай ук подряд килешүе нигезендә төзелеш контроле гамәлгә ашырылган очракта, төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан) имзаланган акт;<br>6) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник шартларга җавап бирүен раслый торган һәм инженер-техник тәэминат челтәрләрен (алар булган очракта) эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларның вәкилләре тарафыннан имзаланган документлар;<br>7) җир кишәрлеге чикләрендә төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының урнашуын, инженер-техник тәэминат челтәрләренең урнашуын һәм җир кишәрлеген оештыру планын чагылдыра торган һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан (төзелешне гамәлгә ашыручы зат һәм төзүче оешма тарафыннан яки, төзелешне, үзгәртеп коруны подряд килешүе нигезендә гамәлгә | |

| | | |
|---|---|---|
| | ашырган очракта, техник заказчы тарафыннан) имзаланган схема, линияле объектны төзү, үзгәртеп кору очракларыннан тыш;<br>8) Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документларын да кертеп) таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин ителү таләпләренә туры килүе турында (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган очракта) дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсе, федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының (алга таба – федераль дәүләт экология күзәтчелеге органы) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 7 өлешендә каралган очракларда бирелә торган бәяләмәсе;<br>9) хәтәр объектта авария нәтиҗәсендә зыян китергән өчен куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә куркыныч объектта авария нәтиҗәсендә зыян китергән өчен хәтәр объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү килешүе төзелүен раслаучы документ;<br>10) «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәдәни мирас объектларын саклау буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты, әлеге объектка реставрация, консервация уздырганда, аны ремонтлаганда һәм заманча файдалану өчен яраклаштырган очракта;<br>11) капиталь төзелеш объектының «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнгән техник планы.<br>Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт алу өчен кирәкле документлар бер нөсхәдә (төп нөсхәсе яисә күчермәсе) яисә ике нөсхәдә тапшырыла, аның берсе | |

| | | |
|---|---|---|
| | төп нөсхәсе, икенчесе мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәсе булырга мөмкин. Документлар ике нөсхәдә тапшырылган очракта, тикшерүдән соң төп нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелә.<br>Дәүләт хезмәтен алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп.<br>Мөрәҗәгать итүче гариза белән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырырга (җибәрергә) хокуклы.<br>Объектларны эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт алуга кирәкле документлар бары тик электрон формада гына, техник мөмкинлек булган очракта, тапшырыла:<br>1) әгәр капиталь төзелеш объектының проект документациясенә экспертиза буенча уңай бәяләмә (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $12^1$ өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда, проект документациясенә дәүләт экология экспертизасы буенча уңай бәяләмә электрон формада тапшырылган булса;<br>әгәр капиталь төзелеш объектына проект документлары һәм (яисә) мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнү нәтиҗәләре, шулай ук проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле башка төр документлар | |

| | | |
|---|---|---|
| | электрон формада тапшырылган булса.<br>Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм теркәлә торган документларны күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшырырга хокуклы. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 1, 2, 3 һәм 8 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), әгәр мөрәҗәгать итүче (төзүче оешма) аларны мөстәкыйль тапшырмаса, Министрлык тарафыннан әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалардан соратып алына.<br>Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 1, 4, 5, 6 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, әгәр әлеге документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булмаган булмаса, мөрәҗәгать итүче (төзүче оешма) тарафыннан мөстәкыйль җибәрелә. Әгәр бу документлар дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булса, әгәр мөрәҗәгать итүче (төзүче оешма) аларны мөстәкыйль тапшырмаса, Министрлык тарафыннан әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалардан соратып алына.<br><br>Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 5 һәм 8 пунктчаларында күрсәтелгән документлар һәм бәяләмәдә капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре составына кертелгән күрсәткечләрнең норматив күрсәткечләре турында һәм төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектына карата үткәрелгән тикшеренүләр, үлчәүләр, экспертизалар, сынаулар нәтиҗәсендә ачыкланган мондый күрсәткечләрнең фактик әһәмиятләре турында мәгълүмат, шулай ук мондый объектның энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм аның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин ителү таләпләренә туры килүен билгеләү өчен нигез булган башка мәгълүматлар була. Күпфатирлы йортны төзегәндә, үзгәртеп корганда дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсендә шулай ук | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнар нигезендә билгеләнә торган күпфатирлы йортның энергия нәтиҗәлелеге классы турында мәгълүмат булырга тиеш.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту:<br>1) әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булмавы;<br>2) капиталь төзелеш объектының капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча төзелешкә рөхсәт алу өчен җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын тапшыру датасына билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки, линияле объектны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау очрагында, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (территорияне планлаштыру буенча документация әзерләүне таләп итми торган линияле объектны төзү, үзгәртеп кору очракларыннан тыш) таләпләренә, урнаштырылуы өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителми торган линияле объектны эксплуатациягә кертү өчен рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проектында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве;<br>3) капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы $6^2$ өлеше нигезендә үзгәртү очракларыннан тыш;<br>4) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары параметрларына туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы $6^2$ өлеше нигезендә үзгәртү очракларыннан тыш;<br>5) капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм (яки) объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирелгән датага җир законнары һәм Россия Федерациясенең бүтән законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә җавап бирмәве, күрсәтелгән чикләмәләр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7 өлешендәге 9 пунктында каралган очракларда кабул ителгән территориядән файдалану буенча махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки әлеге зонаны үзгәртү турында карарда каралган һәм урнаштырылуына бәйле рәвештә территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләнгән яки үзгәртелгән төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объекты эксплуатациягә кертелмәгән очраклардан тыш. | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | Әлеге Административ регламентның 2.6 пункты нигезендә соратылган документларны алмау (вакытында алмау) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту нигезе була алмый. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан чират көтүнең максималь вакыты унбиш минуттан артык булырга тиеш түгел.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга |

| | | |
|---|---|---|
| | | таба – РФ Президентының 601 номерлы Указы) |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Рәсми мөрәҗәгать һәм документлар Министрлыкка алынган көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.<br>Гаризаны һәм теркәлә торган документларны күпфункцияле үзәккә тапшырган очракта, гариза килгән көнендә вазыйфаи күрсәтмә нигезендә гаризаны кабул итү һәм теркәүне гамәлгә ашыра торган күпфункцияле үзәк хезмәткәре (алга таба – КФҮ хезмәткәре) тарафыннан теркәлә.<br>Гаризаны һәм теркәлүче документларны Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Министрлыкка тапшыру тәэмин ителә.<br>КФҮ аша килгән гариза һәм теркәлә торган документлар Министрлыкта килгән көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түбәндәгеләр тәэмин ителә:<br>1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;<br>2) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү; | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы;<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт |

| | | |
|---|---|---|
| объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | 5) инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>6) инвалидлар өчен кирәкле ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү;<br>7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү;<br>9) хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга һәм әлеге пунктның 3-6 пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла | хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:<br>Министрлык һәм күпфункцияле үзәк бинасының җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;<br>Министрлыкның мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>гаризаны «Интернет» челтәрендә Министрлыкның мәгълүмат ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә | 601 номерлы РФ Президенты Указы<br>880 номерлы ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытларын бозулар;<br>дәүләт хезмәтен күрсәткән граждан хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәтен күрсәткән граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Мөрәҗәгать итүченең Министрлыктагы вәкаләтле бүлекчәләрнең белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>гариза белән документларны почта аша җибәргәндә, – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮ читтән торып эшләү урынында тулы күләмендә күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка һәм күпфункцияле үзәккә телдән мөрәҗәгать иткән очракта алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүматларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтыннан, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан алу мөмкинлеге тудырылмаган.<br>Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаның һәм теркәлә торган документларның Министрлыкка тапшырылуы тәэмин ителә.<br>Гаризада мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте нәтиҗәсен КФҮ алуы турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән очракта, Министрлык дәүләт хезмәте нәтиҗәсен КФҮ тапшыруны тәэмин итә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүче белән эшләү тәртибе КФҮ эш регламентында җайга салына.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча да (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта), һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр | Гариза һәм документларның күчермәләре Министрлыкка «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон), 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешкә рөхсәт бирү һәм эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 729 номерлы карары (алга таба – 729 номерлы ТР МК карары) таләпләре нигезендә квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон формада җибәрелә ала | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы;<br>63-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>729 номерлы ТР МК карары |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;
2. гаризаны теркәлгән документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү;
3. гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлылыгын тикшерү;
4. ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү;
5. дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;
6. мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;
7. техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша Министрлыкка дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать иткән ысулы нинди булуга карап, мөрәҗәгать итүчене, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен зарури документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияли һәм мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә.

3.3. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында теркәлгән документлары белән гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат аша яисә почта аша Министрлыкка төбәкара багланышлар һәм документлар үтәлешен тикшереп тору бүлегенә әлеге Административ регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны (документлар күчермәләрен) теркәп, әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасы нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыра.

Документларны тапшырганда мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук, әлеге Административ регламентның

2.5 пунктына ярашлы рәвештә, тапшырылмый торган документларның да исемлеге төзелә.

Тапшырылмый торган документлар исемлегендә аларны биргән органнарның атамалары, теркәлү номерлары, теркәлү даталары, аерым очракларда, тиешле гарызнамәләрне тапшыру өчен кирәкле, аларда булган белешмәләр күрсәтелә.

Гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны, шулай ук хокук күчүе турындагы белдерүне мөрәҗәгать итүче, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда һәм әлеге Административ регламентта белдерелгән таләпләрне үтәп, электрон формада тапшырырга хокуклы.

Документлар электрон формада һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып тапшырган очракта, гариза һәм аңа теркәлә торган документлар, шулай ук хокук күчүе турындагы белдерү 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гаризага кул куйган затның электрон цифрлы имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

3.3.2. Министрлыкта алынган корреспонденцияне теркәү өчен җаваплы булган, Министрлыкның төбәкара башланышлар һәм документлар үтәлешен тикшереп тору бүлегенең вазыйфаи заты (алга таба – документларны теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат) гаризаны һәм документларны Министрлыкның Эшчәнлек башкару күрсәтмәсендә билгеләнгән тәртиптә терки һәм карау өчен вәкаләтле бүлекчәгә җибәрә, шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшырылган гаризаларның ике нөсхәсендә дә алынган номерын куя, аларның берсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра.

Документларны теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат Министрлыкта билгеләнгән эш башкару тәртибендә почта аша, электрон саклагычта, яки, «Интернет» челтәрен дә кертеп, уртак файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып килгән гаризаны терки.

Документларны теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат Министрлыкта билгеләнгән эшчәнлек башкару тәртибендә гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны (документларның күчермәләрен) электрон формада электрон документ әйләнеше системасы аша министрның капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәтләр бирү мәсьәләләрен тикшерүдә тотучы урынбасарына яки аны алмаштыручы затка (алга таба – министр урынбасары) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар Министрлыкка килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Министр урынбасары Министрлыкта билгеләнгән эшчәнлек башкару тәртибендә гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны (документларның күчермәләрен) электрон формада электрон документ әйләнеше системасы аша әлеге Административ регламентның 1.3 пунктында күрсәтелгән җаваплы структур бүлекчәгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар министр урынбасарына шәхсән алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: вәкаләтле бүлекчәгә карау өчен җибәрелгән гариза.

3.3.4. Вәкаләтле структур бүлекчә җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтү өчен

вәкаләтле булган структур бүлекчә вазифаи затын (алга таба – Бүлекнең вазыйфаи затын) (резолюция рәвешендә) билгели.

Дәүләт хезмәте күрсәтү бурычы йөкләнгән бүлекнең вазыйфаи заты Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турындагы гаризаларны теркәү журналына (алга таба – Журнал) алынган гариза турында мәгълүмат кертә .

Журналда түбәндәгеләр күрсәтелә:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырылу датасы (Министрлыкка килү датасы);

мөрәҗәгать итүченең аталышы;

документларны кабул иткән вәкаләтле структур бүлекчәдәге вазыйфаи затның фамилиясе һәм инициаллары;

объектның аталышы һәм килгән документларның (папкаларның, тартмаларның һ.б.) кәгазьләр саны;

объектны файдалануга кертүгә рөхсәт әзерләү датасы;

мөрәҗәгать итүчегә объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәтне (объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирүдән баш тартуны) тапшыру датасы яисә почта аша җибәрү датасы;

объектны файдалануга кертүгә рөхсәтне (документларны теркәп, объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту) алган затның имзасы

искәрмә.

Журнал кулдан язып һәм электрон формаларда, әлеге Административ регламентның 2 нче кушымтасына ярашлы рәвештә алып барыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедура нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

вәкаләтле структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан Бүлекнең вазыйфаи затын билгеләү, электрон документ әйләнеше системасында резолюция рәвешендә рәсмиләштерү;

Журналдагы язу.

3.4. Гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлы булу-булмавын тикшерү.

3.4.1. Бүлекнең вазыйфаи заты тапшырылган документлар җыелмасын әлеге Административ регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килү-килмәве буенча тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар килгән гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның комплектлылыгын билгеләү.

3.5. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү.

3.5.1. Бүлекнең вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнарга, муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнарга, дәүләт хезмәте күрсәтә торган дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларга, ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү эшендә катнаша торган башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына әлеге Административ

регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры китереп белешмәләр алу өчен ведомствоара гарызнамәләр җибәрә.

Ведомствоара мөрәҗәгать электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешентә формалаштырыла һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) каналлары буенча җибәрелә.

Ведомствоара электрон мөрәҗәгатьне электрон документ рәвешендә формалаштыру һәм ВЭХС каналлары буенча җибәрүнең техник мөмкинлекләре булмаганда, ведомствоара мөрәҗәгать кәгазьдә почта аша, бер үк вакытта почта аша яисә курьер ярдәмендә җиткерү юлы белән факс буенча җибәрелә.

Ведомствоара мөрәҗәгать 210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^2$ статьясы таләпләре нигезендә формалаштырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре әлеге Административ регламентның 3.5.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә соралган белешмәләрне (документларны) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә соралган белешмәләрнең булмавы турында Министрлыкка җибәрелгән хәбәр.

3.6. дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.6.1. Бүлекнең вазыйфаи заты түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

документларны рәсмиләштерүнең дөрес булуын тикшерә;

әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәт проектын әзерли һәм аны министр урынбасарына килештерү өчен җибәрә.

Административ регламентның 2.8 пунктында каралган капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту нигезләре булган очракта, рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү проекты әзерли һәм аны министр урынбасарына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен министр урынбасарына җибәрелгән рөхсәт проекты яки баш тарту турында белдерү проекты.

3.6.2. Министр урынбасары объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт проектын яки баш тарту турында белдерү проектын карый һәм килештерә һәм кул кую өчен министрның беренче урынбасарын җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә

ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына кул кую өчен юнәлдерелгән, килештерелгән проектлар.

3.6.3. Министрның беренче урынбасары капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәт яисә баш тарту турында белдерү кәгазенә кул куя һәм Бүлекнең вазыйфаи затына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган рөхсәт яки белдерү.

3.6.4. Бүлекнең вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчегә, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рөхсәт бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.7.1. Бүлекнең вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчегә капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рәсмиләштерелгән рөхсәт яки баш тарту турында белдерү тапшыра (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар 15 минут эчендә, чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне яки рөхсәт (баш тарту турында белдерү) имзалаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр мондый рөхсәт (баш тарту турында белдерү) электрон документ формасында җибәрелсә.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) рөхсәт яки баш тарту турында белдерү.

3.8. техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата булуы ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкның Министрлыкка алына торган корреспонденцияне теркәү өчен җаваплы булган төбәкара багланышлар һәм документлар үтәлешен тикшереп тору бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Административ регламентка 4 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан Министрлыкка шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә) җибәрелә.

3.8.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны кушып тапшырылган документлары белән

бергә терки һәм аларны вәкаләтле бүлеккә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Бүлекнең вазыйфаи заты документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, әлеге Административ регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып, тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Техник хатасы булган документ мөрәҗәгать итүчегә электрон формада бирелгән булса, Бүлек белгече төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып тапшыра яисә, бу хакта гаризада күрсәтелгән булса, электрон документ формасында җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Төзелеш комплексын үстерү идарәсе җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Көндәлек тикшереп тору Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Административ регламентта һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Министрлыктагы вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылышына, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлешенә;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (әлеге Административ регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Министрлык актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Административ регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеле торган норматив хокукый актлардагы таләпләр бозылуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне һәм шикаятьләрне судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сәбәпле министр тарафыннан кабул ителгән

карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә монополиягә каршы органга белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://minstroy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, КФҮ (http://mfc16.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый

актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

## 6. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) гаризаны Министрлыкка җибәрү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен КФҮ шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына тапшыра.

6.3.2. КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар КФҮ эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

5.4. Гаризаны Министрлыкка җибәрү.

6.4.1. Күпфункцияле үзәк белгече Министрлыкка гариза җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык һәм күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – Министрлыкка юлланган гариза.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.5.1. Министрлык тарафыннан бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документтагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы заты аша күпфункцияле үзәккә язмача тапшыра.

КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Министрлыкка юллау.

6.6.1. Күпфункцияле үзәк белгече Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Министрлыкка җибәрә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына

кемнән: ______________________________________

(юридик зат – төзелешне гамәлгә ашыруны планлаштыручы төзүченең аталышы,

______________________________________

капиталь ремонтлауны яисә үзгәртеп коруны; ИНН; юридик һәм почта адресы;

______________________________________

житәкчесенең ФИА; телефоны, банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

**Файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында**
**гариза**

Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәт бирүегез турында үтенәм ______________________________________

(объект атамасы)

түбәндәге адрес буенча җир кишәрлегендә урнашкан: ______________________

(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)

Төзелеш (үзгәртеп кору) ____ елның «____» ________________ №__ _________ ______________________________ нигезендә гамәлгә ашырылды.

(документ исеме)

Җирдән файдалану хокукы беркетелде ______________________________ ______________________ «____» ____________________ ел, №_______________.

(документ исеме)

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Капиталь төзелеш объектын төзүне (үзгәртеп коруны, капиталь ремонтлауны) төзүче оешма тарафыннан финанслау гамәлгә ашырылды ______________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр подряд (хуҗалык) ысулы белән уздырылды, түбәндәге килешү нигезендә: «____»______________20_____ел. № ______________________________

______________________________________

(оешма атамасы, ИНН, юридик һәм почта адреслары, житәкченең ФИА, телефон номеры, банк реквизитлары (банк атамасы, и-х/сч, к/сч, БИК)

______________________________________

Төзелеш-монтаж эшләрен башкару хокукы беркетелгән ______________

______________________________________

(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың аталышы)

______________________ «____» ____________________ ел, №_______________.

Эшләрне башкаручы итеп ______________________ «____»____________ ел, № ______ боерык нигезендә ____________________ билгеләнде, ул __________

махсус

(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме) (югары, урта)

белемгә ия һәм төзелештәге эшләү стажы ___ ел.

Төзелеш контрольлеге «___»________ ел, № _____________ килешү нигезендә түбәндәге тарафыннан гамәлгә ашырылды:__________________________________

(оешма атамасы, ИНН, юридик һәм почта адреслары, җитәкченең ФИА, телефон номеры, банк реквизитлары (банк атамасы, и-х/сч, к/сч, БИК)

________________________________________________________________________________

заказчы (төзүче) функцияләрен башкару хокукы беркетелде ________________

________________________________________________________________________________

(документ исеме һәм аны биргән оешма аталышы)

______________________ «____»___________________ ел, №______________.

Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында ________________________________________ хәбәр итәргә сүз бирәм.

(вәкаләтле орган атамасы)

____________________ ________________ ____________________________

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.)

«_» _____20_ ел. Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

## Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турындагы гаризаларны теркәү журналы

| Тәртип саны | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырылу датасы (Министрлыкка килү датасы) | Мөрәҗәгать итүче | Документларны кабул иткән вәкаләтле структур бүлекчәдәге вазыйфаи затның фамилиясе һәм инициаллары | Объектның аталышы һәм килгән документларның (папкаларның, тартмаларның h.б.) кәгазьләр саны | Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт әзерләү датасы | Мөрәҗәгать итүчегә объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт тапшыру датасы | Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт (объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту) алган затның имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *1* | *2* | *3* | *4* | *5* | *6* | *7* | *8* | *9* |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

## Объектларны файдалануга кертү өчен бирелгән рөхсәтләр реестры

| Тәртип саны | Керүче документның номеры һәм датасы | мөрәҗәгать итүче | Объектның исеме | Рөхсәт датасы һәм номеры | Рөхсәтнең гамәлдә булу чоры | Чыга торган документның номеры һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *1* | *2* | *3* | *4* | *5* | *6* | *7* | *8* |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

кемгә: Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына ___________

кемнән: ______________________________________________________

(юридик зат – төзелешне гамәлгә ашыруны планлаштыручы төзүченең аталышы,

______________________________________________________

капиталь ремонтлауны яисә үзгәртеп коруны; ИНН; юридик һәм почта адресы;

______________________________________________________

җитәкчесенең ФИА; телефоны, банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)

**Техник хата төзәтү турында гариза**

Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен 20__ елның _____ № ___ рөхсәттә ______________________________________________

(объект атамасы)

түбәндәге адрес буенча җир кишәрлегендә урнашкан: ____________________

(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)

техник хата җибәрелгән.

Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәттә болай дип язылган ________________________________________________

(кирәклесен язарга)

Түбәндәгеләргә нигезләнеп: ______________________________________

(документның исеме һәм реквизитларын күрсәтергә)

дөрес язу_______________________________________________________

(кирәклесен язарга)

Бәян ителгәннәргә нигезләнеп түбәндәгеләр хакында сорыйм:

1. Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүгә 20__ елның ___________ № ____ рөхсәттә җибәрелгән техник хатаны төзәтергә;

2. Югарыда күрсәтелгән капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен төзәтелгән рөхсәт бирү.

Техник хатаны төзәтү өчен тапшырылган документлар һәм гаризада күрсәтелгән белешмәләр төгәл.

Техник хатаны төзәтү турында документларны кабул итү турындагы язуны алдым.

| | | |
|---|---|---|
| _________________ | _______________ | _________________________ |
| (вазыйфа) | (имза) | (Ф.И.А.) |

«___» ______________ 20____ел. М.У. (булган очракта)

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының капиталь төзелеш
объектларын файдалануга кертүгә рөхсәтләр
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына (белешмәлек)
кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары | **231-14-03** | Aleksey.Frolov@tatar.ru |
| Министр урынбасары | **231-14-05** | Ilshat.Gimaev@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | **231-17-08** | Dinar.Sagdatullin@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | **231-14-57** | Dmitriy.Yasakov@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестицияләү программаларын гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе | **264-77-24** | Yuriy.Azin@tatar.ru |